ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЗЕЛЕНОРОЩИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗЕЛЕНАЯ РОЩА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е КАРАР

2021 елның 21 октябре № 26

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 29 октябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 29 октябрендәге 12 номерлы карары белән расланган:

Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Нотариаль гамәлләр – ышанычнамә таныклыгы кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Агач һәм куаклар кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш ур., 1 йорт, Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасы, Спиридоновка авылы, Совет урамы, 32 нче йорт Спиридоновка авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
“Зеленая Роща җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.А.Потапов.